РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 сентябре № 43

## Шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга дәүләт ярдәме чаралары, шул исәптән мөлкәти, күрсәтү мөмкинлеге максатларында, Түбән Кама шәһәр Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының – ярдәм алучыларның бердәм реестрын формалаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьялары нигезендә, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба – үзмәшгуль гражданнар) дәүләт һәм муниципаль ярдәм чаралары, шул исәптән мөлкәти, күрсәтү мөмкинлеге максатларында, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2018 елның 23 гыйнварындагы 5 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, Муниципаль милек исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба – үзмәшгуль гражданнар)» сүзләрен өстәргә;

1.2. Түбән Кама шәһәр Советы карары белән расланган Тәртипнең 1.1 пунктында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгуль гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктта «Исемлеккә кертелгән мөлкәт арендаторлары булып, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары торырга мөмкин» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләр» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин